**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе Таҗи Гыйззәт исемендәге 3нче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

# Тема: "Рәвеш" темасын кабатлау

**6нчы сыйныф (татар төркеме)**

**Сингапур укыту методын кулланып уздырылган ачык дәрес эшкәртмәсе**

**Укытучы: Ишмөхәммәтова В.М.**

**15 март 2014**

**Дәреснең темасы:** “Рәвеш” темасын кабатлау.

**Дәреснең максатлары:**

**1. Белем бирү максаты -** Укучыларның “Рәвеш” темасы буенча алдагы дәресләрдә өйрәнгән белемнәрен (мәгънәсен, сорауларын, кушымчаларын, төркемчәләрен) тикшерү, сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәтү.

**2. Фикер сәләтен үстерү максаты -** Укучыларның логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын һәм танып-белүне үстерүгә ярдәм итү.

**3. Тәрбияви максат -** Аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру.

**Җиһазлау:** компьютер, карточкалар, төсле кәгазь битләре, структураларның алгоритмы, МЭНЭДЖ МЭТ, таймер, татар теле дәреслеге.

**Дәреслек:** Максимов Н.В., Хәмидуллина М.З. Татар теле. 6нчы сыйныф: - Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010

**Дәрес тибы:** белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру.

**Кулланылган структуралар:**

МЭНЭДЖ МЭТ

СИНГЛ РАУНД РОБИН

ФРЕЙЕР МОДЕЛЕ

МИКС-ФРИЗ-ГРУП

КОНЭРС

ДЖОТ ТОТС

ТИК-ТЭК-ТОУ

КОНТИНИУС РАУНД РОБИН

## Дәрес барышы

**1. Оештыру.**

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру. Хәерле көн теләү. Кунаклар белән исәнләшү.

Дежур укучыны тыңлау. (Өй эше – “Рәвеш” темасын кабатларга)

Дәреснең максаты белән таныштыру.

- Укучылар, бүген без сезнең белән дәрестә рәвеш сүз төркемен кабатларбыз, ныгытырбыз, белемнәрне системага салырбыз. Дәрес ахырында без аңларга тиеш: бу тема буенча без нәрсәләрне яхшы беләбез, ә нәрсәләрне әле безгә яңадан ныгытырга кирәк булачак. Һәм безнең икенче максат – бу контроль эшкә әзерләнү. Аңлашылдымы?

- Балалар, ә сез ничек уйлыйсыз, бүген дәрестә “Рәвеш” темасы буенча без нәрсәләрне кабатларбыз икән? Сез әйтегез, ә мин тактага язып куям. (Кагыйдә, төркемчә, ясалышын, язылышы, җөмләдә кулланылышы...

**2. Актуальләштерү.**

Проблемалы сорау кую.

- Балалар, ә сез ничек уйлыйсыз, без бу теманы ни өчен өйрәндек? Рәвешләрне без кайда, ничек кулланырбыз? Әйдәгез әле, шул турыда төркемнәрдә бергәләп уйлашыйк. Һәрберегез үз фикерен әйтергә тырышсын. СИНГЛ РАУНД РОБИН структуасы. Сезгә 1 минут вакыт бирелә, аннары һәр өстәлдән берәр фикерне тыңларбыз. (Укучыларның җаваплары тыңлана).

- Нинди нәтиҗәгә килдек? (-Рәвешләрне өйрәнергә кирәк!)

-Менә сез аларны нинди дәрәҗәдә өйрәндегез микән, әйдәгез әле, тикшереп карыйк. Без аны ФРЕЙЕР МОДЕЛЕН кулланып тикшерербез.

Укучылар, сезнең алда альбом битләре ята, башта аны икегә, аннан тагын икегә бүләбез. Шул бүленгән кисәкнең бер почмагын әз генә бөклибез һәм альбом битен вертикаль рәвештә ачып каршыбызга куябыз. Әлеге битнтәге бөкләнгән урыннарны карандашлар белән кабатлап чыгабыз һәм уртага *рәвеш* дип язабыз. Беренче баганага рәвешнең билгеләмәсен, икенче баганага характеристикасын, өченче баганага мисаллар, дүртенче баганага капма-каршы мисалларны язабыз. Һәр кәгазь битен мөстәкыйль рәвештә тутырабыз. Сезгә барлыгы 3 минут вакыт бирелә.

**Билгеләмә**

Рәвеш – эшнең яки хәлнең билгесен белдерә. Нигә? Кайчан? Кайда? сорауларына җавап бирә.

**Характеристика**

6 төркемчәсе
Дәрәҗәләре бар
Фигыльне... ачыклый
Җөмләдә хәл... була
Мөст. сүз төркеме

**РӘВЕШ**

**Мисаллар**

тиз
бүген
юри
бушлай

**Капма-каршы мисаллар**

бара
сөйли
ике
өстәл

- Вакыт чыкты. Әйдәгез, тикшерәбез. (Җаваплар тыңлана, тулыландырыла.)

**3. Кабатлау, ныгыту.**

- Ясалышы буенча нинди төрләргә бүленә?

(Тактада укучы схемасын ясый: тамыр, ясалма, тезмә, парлы, кушма. Мисаллар китерәләр)

- Тикшереп карыйбыз: барыбыз да аера беләбезме икән? Хәзер мөстәкыйль эшләр өчен карточкалар өләшәм. Анда бирелгән җөмләләрдән А варианты ясалма һәм тезмә рәвешләрне күчерә, Б варианты – кушма һәм парлыларны. Бу эшкә 4 минут вакыт бирелә. Дәфтәрләргә матур итеп числоны язабыз һәм эшли башлыйбыз.

- Вакыт бетте. Эшләрне тәмамлыйбыз. Хәзер дәфтәрләрне алышып тикшерәбез. Ничәсе дөрес – билге шундый. “5” леләр бармы? Тактада язылган сүзләр:

| **А** | **В** |
|---|---|
| Шул килеш | Бераз |
| Картларча | Кайвакыт |
| Кичен | Куна-төнә |
| Иртән | Бүген |
| Бушлай | Елдан-ел |

**Физкультминут**

(*МИКС – ФРИЗ – ГРУП* структурасының эчтәлеген шигырь белән аңлатам. Шигырьдә рәвешләр дә бар.)

- Ә хәзер, укучылар,
Әкрен генә басабыз
Әзрәк уйнап алабыз
Артислардай биибез
Аннан туктап калабыз
Мин биргән сорауларга
Тиз генә җавап табабыз.

Уйнар алдыннан минем соравым бар: игътибар иткәнсез микән, мин хәзер сезгә рәвешләр кулланып сөйләдем. Ничә рәвеш кулланганымны әйтсәгез, уйныйбыз. (Яңадан кабатлыйм) - 6. - Әфәрин! Ә хәзер *МИКС – ФРИЗ – ГРУП*

1. Татар телендә ничә килеш бар? (6)
2. Сыйфатларның ничә дәрәҗәсе бар? (4)
3. Саннарны язганда ничә төрле цифр кулланабыз? (2)
4. “Рәвеш” сүзендә ничә тартык бар? (3)
5. Рәвешләрнең ничә төркемчәсе бар? (6)

(Сорауларга җавап бирер алдыннан уйлыйлар)

- Нинди төркемчәләр? Сүзләрнең нинди төркемчәдә икәнен аера белүегезне почмаклар ярдәмендә тикшерербез. Мин сезгә төрле төркемчәдәге рәвешләр язылган карточкалар өләшәм. Сүзләрегез нинди төркемчәгә керә, шул почмакка басасыз. Бер-берегезгә сүзләрне укыйсыз, тикшерәсез һәм шул төркемчә турында сөйләргә өйрәнәсез. 2 минут вакытыгыз бар.

- Тикшерәбез. (Укучылар сүзләрен укып чыгалар, сорауларын, кагыйдәсен әйтәләр)

- Рәхмәт, утырдык. Ә хәзер үзегезгә ошаган рәвешләрне кәгазь битләренә язып, дусларыгыз белән уртаклашыгыз. Бу безнең ДЖОТ ТОТС структурасы. Битләрне 2нче номерлы укучылар өләшә. Берәр сүз язасыз, укыйсыз, уртага куясыз. Аннары 1нче номер сүзләрне сайлап ТИК-ТЭК-ТОУ структурасы буенча эшләргә әзерли. Башта 1 мин уйлыйсыз. Аннары эшләргә 3 минут вакыт бирелә.

- ТИК-ТЭК-ТОУ структурасы буенча сүзләрдән җөмләләр төзергә кирәклеген беләсез. Сүзләрне я диогональ, я вертикаль, я горизонталь буенча алырга кирәклеген онытмыйбыз. Берәр җөмләне дәфтәргә язабыз. Аннары бер-беребезгә укыйбыз. Тикшерәбез. Өстәлдән укырга берәр җөмлә сайлыйбыз. (КОНТИНИУС РАУНД РОБИН структурасын кулланабыз.)

3нче номерлы укучы өстәлдә тәртип урнаштыра.

- Укучылар, әйтегез инде миңа: бүген дәрестә нәрсәләр эшләдек, нәрсәләрне кабатладык, нәрсә эшләргә өйрәндек? (- Рәвешләрне җөмләдә кулланырга)

Өй эше: (укучылар үзләре сайлап алалар)

1. Әдәби әсәрләрдән, газета-журналлардан рәвешләр кергән 5 җөмлә күчерергә.

2. Рәвешләр кулланып, “Бүген көнем ничек үтте?” исемле хикәя төзеп язарга.

- Менә без сезнең белән “Рәвеш” темасын кабатлап чыктык. Хәзер әйтегез әле: бу теманы кем “5”легә үзләштердем, дип уйлый. Кем белемен “4”лелек ди? Ни өчен? Ә кем үзенә “3”ле куя? Ни өчен? Бу теманы ныгытырга безнең әле тагын дәрес бар.

Тырышлык булса, уңышлар да булыр!

Сау булыгыз, укучылар!